ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
Идел буе авыл җирлегенең Ржавец торак пунктында
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының

30.10.2025 №2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлегенең Ржавец торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

Карар кылдым:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Идел буе авыл җирлегенең Ржавец торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

1) Ржавец торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны кардан чистарту, территорияне чабу (МТЗ – 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу));

2) Идел буе торак пунктында традицион Күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (киртәләр кору (төзелеш материалы сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү), агачлар, куаклар кисү (эшләр өчен килешү буенча түләү)).

3. Әлеге карарны Идел буе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга ( http:// spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Идел буе авыл җирлеге башлыгы
Спас муниципаль районы С. Г. Спирин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ПРИВОЛЖСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ ПРИВОЛЖСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ